**2019 елда Яр Чаллы шәһәренең җирле үзидарә органнарына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләр белән эшләү турында**

2019 елда җирле үзидарә органнарында гражданнар тарафыннан язмача җибәрелгән һәм шәхси кабул итүдә алынган **9 032** мөрәҗәгать каралды (2018 елда – **9 175** мөрәҗәгать).

Барлык кергән мөрәҗәгатьләрнең гомуми саныннан:

Язмача мөрәҗәгатьләр саны – **5 315** (2018 елда – **5 842**). Язмача мөрәҗәгатьләр узган елның шул чоры белән чагыштырганда **527** мөрәҗәгатькә кимеде һәм ул 9% ны тәшкил итте.

**3 958** язмача мөрәҗәгать электрон рәвештә алынды (ведомствоара электрон документлар әйләнеше, Интернет-кабул итүе һәм электрон почта аша) (2018 елда – 3 943).

**1 357** мөрәҗәгать шәһәрнең җирле үзидарә органнарына кулдан (кулга, почта, курьер аша) бирелде (2018 елда – 1899)**.**

Татар телендә **42** мөрәҗәгать керде (2018 елда – 24).

Шәһәр Хакиме һәм Башкарма комитет Җитәкчесе исеменә барлыгы 10 450 имза белән 261 коллектив мөрәҗәгать алынды (2018 елда – 6 493 кешедән 219 коллектив мөрәҗәгать)**.** Коллектив мөрәҗәгатьләрне имзалаучылар саны – 3 957 кешегә, ә коллектив мөрәҗәгатьләр саны 42 гә арткан.

Шәһәр Хакименә һәм Башкарма комитетның структур бүлекчәләренә шәһәр халкын борчыган мәсьәләләрне хәл иткән өчен рәхмәт белдерелгән 36 хат алынды.

Гражданнарның бер генә мөрәҗәгате дә җирле үзидарә органнарында игътибарсыз калмый.

5 315 мөрәҗәгатьнең 909 ы уңай хәл ителде һәм бу гомуми санның 17% ын тәшкил итте, 99 ы ведомство буйсынуындагы оешмаларга адресланды, калган мөрәҗәгатьләр буенча аңлатмалар һәм рекомендацияләр бирелде.

Үзләренең социаль хәлен күрсәтүчеләрнең составы түбәндәге категория гражданнарга бүленә:

- пенсионерлар: 451 (8,49%);
- эшләүчеләр: 284 (5,34 %);
- эшсезләр: 105 (1,98%);
- эшмәкәрләр: 85 (1,59%);
- хуҗабикәләр: 63 (1,19%);
- хезмәткәрләр: 63 (1,19%);
- интеллигенция: 53 (0,99%)
- укучылар: 12 (0,23%);

- социаль хәлен күрсәтмәүчеләр: 4199 (79,00%).

Мөрәҗәгать итүчеләр арасында үзенең льготалы категориягә ия булуын күрсәтүчеләрнең күпчелеге: инвалидлар – 193 (3,63%), күп балалы гаиләләр – 134 (2,52%), хәрби хәрәкәттә катнашучылар һәм ветераннар (сугышчы-интернационалистлар) – 18 (0,34%), ялгыз ата-аналар – 17 (0,32%), Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм инвалидлар – 5 (0,10%), Бөек Ватан сугышы елларындагы тыл хезмәтчәннәре – 2 (0,04%).

Гражданнардан кергән язмача мөрәҗәгатьләрне анализлау шуны күрсәтә, 2019 елда шәһәр халкы өчен түбәндәге мәсьәләләр аеруча актуаль саналган:

- торак-коммуналь хуҗалыгы һәм шәһәрне төзекләндерү – 1956 (36,80%);

- мәгариф һәм мәктәпкәчә тәрбия бирү – 515 (9,69%);

- төзелеш – 510 (9,59%);

- җирдән файдалану – 373 (7,02%);

- юл хуҗалыгы – 363 (6,83%);

- торак өлкәсе – 311 (8,04%);

- сәүдә һәм кулланучылар хезмәте – 190 (3,57%);

- транспорт – 158 (2,97%);

- финанс өлкәсе – 151 (2,84%);

- законлылык һәм хокук тәртибен тәэмин итү – 150 (2,82%);

- социаль өлкә – 149 (2,80%);

- сәламәтлек саклау – 123 (2,31%);

- хезмәт һәм эш хакы – 97 (1,83%);

- элемтә – 59 (1,11%).

**3 717** чаллылы шәхси кабул итүдә булган (2018 ел белән чагыштырганда 384 кә артык (2018 елда – 3 333).

1 221 мөрәҗәгать буенча чаралар күрелде, мөрәҗәгать иткән 2 468 граждан аңлатмалар алды, 28 мөрәҗәгать контрольдә тора.

Шәһәр Хакиме һәм Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан 351 чаллылы турыдан-туры кабул ителде.

Чагыштыру анализы күрсәткәнчә, алдагы еллардан аермалы буларак, шәһәр Хакименең Җәмәгатьчелекне кабул итү бүлмәсенә урта яшьтәге гражданнар шәхсән ешрак мөрәҗәгать итә башлаганнар:

-18 яшьтән 35 яшькә кадәр – 131 кеше (21,7%);

-35 яшьтән 55 яшькә кадәр – 261 кеше (43,4%);

-55 яшьтән өлкәнрәк – 210 кеше (34,8%).

Шәхси кабул итүдә телдән мөрәҗәгатьләр белән 350 хатын-кыз һәм 252 ир-ат булган.

Кергән мөрәҗәгатьләрнең мониторингы көн саен уздырыла, мөрәҗәгатьләрне үзвакытында карау контрольдә тотыла, үтәү дисциплинасы буенча анализ ясала.

Җирле үзидарә органнарына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрдә бәян ителгән мәсьәләләр компетенция кысаларында оператив рәвештә хәл ителә.

Мөрәҗәгать итүче һәр кешегә гамәлдәге законнарга нигезләнеп язмача җаваплар һәм аңлатмалар бирелде.